| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 декабрь г.Казань № 1254

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 февраль, 175 нче карары белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү буенча комитет составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 июль, 175 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 11 март, 149 нчы; 2011 ел, 10 февраль, 83 нче; 2015 ел, 16 февраль, 95 нче, 2019 ел, 8 февраль, 83 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү буенча комитет составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комитет составыннан Р.Ю.Беляковны, З.Ф.Гыймаевны, Г.Р.Нигъмәтуллинаны чыгарырга;

Комитет составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Зарипов Айрат Ринат улын | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисен (килешү буенча) |
| Карпов Александр Андреевичны | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциячел булмаган автоном оешмасы генераль директорын (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Низамова Ләйсән Гаптелхан кызын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгын |
| Хисамеев Марат Рамил улын | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары - Гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек итү идарәсе башлыгын (килешү буенча) |
| Шиабиев Альберт Хаҗи улын | Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге идарәсе рәисен (килешү буенча); |

Вәлиев Разил Исмәгыйль улы вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыятенең генераль директоры киңәшчесе»;

Галимова Лилия Камил кызы вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты Матбугат хезмәте җитәкчесе (килешү буенча)»;

Ратникова Римма Атлас кызы вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты әгъзасы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин